КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 4 ноябрь г.Казань № 1050

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» 2018 ел, 11 июль, 563 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» 2018 ел, 11 июль, 563 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 4 март, 151 нче; 2020 ел, 26 март, 221 нче; 2020 ел, 16 июнь, 496 нчы; 2020 ел, 9 ноябрь, 1004 нче; 2021 ел, 13 август, 712 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үз вәкаләтләре чикләрендә балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмалары реестрында булган балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмалары турындагы мәгълүматларның дөреслегенә, актуальлегенә һәм тулылыгына төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) (04.07.01*).»;

---

* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы буенча.

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 73 пунктча өстәргә:

«73) балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмалары реестрында булган балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмалары турындагы мәгълүматларның дөреслегенә, актуальлегенә һәм тулылыгына төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыру.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин